2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында гражданнарның үзара салым кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАРЫ

2022 елның 21 декабре №10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Монаш авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 1. 2023 елда Менделеевск муниципаль районының Монаш авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә гражданнардан үзара салым җыюны гамәлгә кертергә, балигъ булмаган балаларын тәрбиядә тотучы күпбалалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы студентлары, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнарга, әлеге категориядәге гражданнар өчен 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, I и II группа инвалидларны түлзүдән азат итәргә.
2. 2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә
   1. Тынычлык урамы буенча агачларны кисәргә.

3. Мәгълүмат тактасында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыенының нәтиҗәләрен игълан итәргә: Монаш авылы, Мәктәп урамы, 19 йорт, һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Монаш авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Монаш авыл җирлеге башлыгы

Р.Ф. Иосифов